Казан (Идел буе) федераль университеты газетасы

# DARELFØNYN
УНИВЕРСИТЕТ

№ 4 (17)

16 февраль 2012 ел

## • Ике авыз сүз

9 февраль көнне юридик факультетта Гыйльми совет утырышы узды. Биредә Төркиянең иң эре югары уку йортларының берсе булган Едитепе университетын тәкъдим итү булды. Стамбул мәгариф һәм мәдәният фонды тарафыннан 1996 елда нигезләнгән әлеге уку йортында 20 меңнән артык студент инглиз, немец, төрек телләрендә белем ала.

Факультетның Европа һәм халыкара хокук кафедрасы аспиранты Фәридә Вәлиуллина Едитепе университетына сәяхәте, ректор Нурҗан Бач һәм юридик факультет деканы Халук Кабаалыоглы белән очрашуы турында сөйләде. Ике уку йорты арасындагы багланышларга басым ясап, ул тыгыз хезмәттәшлек мәсьәләләренә тукталды. Ф.Вәлиуллина сүзләренә караганда, Казан университетының юридик факультеты озакламый ELFAда (Юридик факультетларның Европа ассоциациясе) катнашырга җыена.

Май башында Едитепе университеты вәкилләре безнең уку йортына киләчәк. Ике университет арасындагы багланышлар турында сөйләшү көтелә.

• • • •

13 февраль КФУ һәм А.Н.Туполев исемендәге Казан милли тикшеренү техник университеты арасында фракталь структуралар синтезы технологияләре һәм катлаулы техник системалар лабораториясе булдыру турындагы килешүгә кул куелды. Лаборатория вузара һәм фәнара багланышлар даирәсен тагын да киңәйтә. Ректор Илшат Гафуров сүзләренә караганда, мондый документка ихтыяҗ инде күптән булган. 80 ел элек КДУның аэродинамика факультеты базасында оешкан КАИ бүген, безнең университет кебек үк, яңа дәрәҗә һәм матди-техник мөмкинлекләргә ия. «Уку йортларына бер үк өлкәдә бер-берсен кабатлап, бер-берсенә көндәш булып утыру кирәк түгел», – диде Илшат Гафуров үзенең чыгышында.

• • • •

14 февраль көнне Илшат Гафуров РФнең Хөкүмәт рәисе Владимир Путин белән узган очрашуда ректор буларак кына түгел, ә Президентлыкка кандидатның ышанычлы кешесе буларак катнашты. Очрашуда бик күп мәсьәләләр күтәрелде. Студентлар өчен иң яхшы яңалык: сентябрь аеннан стипендия – 5 мең, аспирантларныкы 6 мең булачак. Шулай ук ассистентларның да хезмәт хакы артачак.

Ректор И.Гафуров Хөкүмәт рәисе һәм МДУ ректоры В.Садовничийдан соң чыгыш ясады. Ул социаль, Россия Президенты стипендияләренә кагылышлы сорауларны күтәрде. Аның фикеренчә, бу стипендияләр күләменең махсус стипендиялərдән калышуы дөрес түгел. Шулай ук ректор җитәкчегә салым буенча законга үзгәреш кертергә тәкъдим итте, чөнки чыгымга китерүче проектларда катнашуның кирәге юк. В.Путин әлеге сорауларны карарга сүз бирде. Очрашу барышында шулай ук яшь белгечләргә илебездә үсәргә мөмкинлек биргән грантлар, заманча фәнни-тикшеренү лабораторияләре булдыру кебек мәсьәләләр дә каралды.

• • • •

Бүген Универсиада авылында «Гадел сайлаулар өчен» митингы узды. Студентлар үзләренең актив гражданлык позициясендә булуын күрсәтте һәм башкаларны да Россия Федерациясе Президентын сайлауда катнашырга чакырды. Әлеге митинг ниндидер кандидатларны пропагандалауны максат итеп куймады. Чара активистлар тарафыннан күптәннән планлаштырылган һәм Казан мэриясе, КФУ ректоры белән килешенгән. Илшат Гафуров: «КФУ студентларының шундый актив гражданлык позициясе өчен шатмын», – дип белдерде.

• • • •

Иртәгә, ягъни 17 февраль көнне сәгать 12дә «УНИКС»та «Кризисның сәбәпләре. Казан, Россия һәм дөньяны 2012 елда ни көтә?» дигән темага лекцияләр узачак. «Казанда «креатив сыйныф»ның перспективалары» дигән тема буенча Казан шәһәре мэры Илсур Метшин чыгыш ясаячак. Дөнья буйлап сибелгән каршылыклар дулкыны хакында International Academy of Science академигы, МДУ галиме Андрей Фурсов сөйлиячәк. «Сары инкыйлаблар»ның технологияләре: Сербия, Украина һәм Мисырдан Россиягә кадәр» темасын исә күп еллар дөньякүләм демократиягә бәйле мәсьәләләрне өйрәнгән сәясәт фәннәре докторы, Мәскәү дәүләт халыкара багланышлар институты профессоры Елена Пономарева яктыртачак.

*ksu.ru сайты материаллары файдаланылды.*



Сергей Тәбин фотосы

# Багланышларны киңәйтеп

**Динара ӘХМӘТОВА,**
хәбәрче

13-15 февраль көннәрендә Казан федераль университетында Франциянең Страсбург университеты профессоры Александр Варнек булды. Ул университет җитәкчелеге, укытучылар һәм студентлар белән очрашты.

Страсбург университеты безнең уку йорты белән 2003 елдан бирле хезмәттәшлек итә. Ә 2011 елның ноябрь аенда ректор Илшат Гафуров Страсбург университетына визит барышында халыкара килешүгә кул куйды. Якын киләчәктә ике уку йорты уртак лабораторияләр ачуны күздә тота. А.М.Бутлеров исемендәге Химия институтында уртак «Химик информатика», «Даруларны структур-биологик тикшерү» лабораторияләре яшь галимнәргә яңа ачышлар ясарга ярдәм итәчәк. Шулай ук Хисаплау математикасы һәм мәгълүмати технологияләр институты һәм Физика инститиуты белән берлектә бик күп проектлар тормышка ашырылачак.

«Алгарыш» программасы ярдәмендә Страсбург университетында магистрлар әзерләү планлаштырыла. Бүгенге көндә профессор Марат Юсупов җитәкчелегендә биохимия белгечлеген алган Искәндәр Хөсәинов аспирантурада укый. 2013 елда «Хемоинформатика һәм молекуляр модельләштерү» юнәлеше буенча Россиядә беренче магистратура ачылачак. Бу, әлбәттә, белгечләр, әлеге өлкә буенча махсус дәреслекләр, программалар булдыруны таләп итә. Профессор Варнек катнашында яңа китаплар да бастырылачак.

«Алдан ук ниндидер күзаллаулар белән яшәү дөрес түгел. Төп нәтиҗәне 3-4 елдан гына әйтә алырбыз. Быел ук берничә магистр программасы, уртак аспирантура булдырылачак. Бу башта яхшы белем алу булса, киләчәктә яхшы эш белән тәэмин ителү дигән сүз. Безнең ил, Татарстан алга барса да, әлеге өлкәләрдән күпкә артта кала. Аларны үстерү өчен, югары белемле белгечләр кирәк», – диде ректор Илшат Гафуров.

Теоретик химия һәм хемоинформатика өлкәсендә 30 елдан артык тәҗрибәсе булган галим Варнек А.М.Бутлеров исемендәге Химия институты студентларына кызыклы лекция тәкъдим итте.

## • Сайлаулар - 2012

# Гаделлек сагында

**Динә МӨХТӘСИПОВА,**
хәбәрче

10 февраль көнне Россиянең юристлар ассоциациясе оештырган «Чиста сайлаулар өчен» күзәтүчеләр корпусы активистлары юридик факультет студентлары белән очрашты. Ул 4 мартта узачак РФ Президентын сайлауга багышланды.

Татарстанда сайлау участокларына 2853 гражданны күзәтүче итеп алачаклар. Россия буенча әлеге эшкә 96 мең яшь юрист җәлеп ителәчәк. Шул уңайдан ассоциация активистлары беренче булып КФУ студентларына мөрәҗәгать итте. Ректор Илшат Гафуров, студентларны сайлауларда актив катнашырга чакырып: «Нәкъ менә сез, яшь буын, сайлауларда күзәтүче буларак эшләп, нәтиҗәләр буенча фикерегезне җиткерә алырсыз», – диде. Очрашу барышында вуз җитәкчелеге күзәтүчеләргә транспорт, калган дәресләр мәсьәләсендә ярдәм итәчәген җиткерде. Шулай ук ректор Корпус вәкилләренә күзәтүчеләрне КФУда укытырга тәкъдим итте.

Күзәтүче булып эшләү өчен, гаризаны 18-35 яшьлек юридик факультет студентлары, аспирантлар яисә актив гражданлык позицияле катнаш факультет студентлары 25 февральгә кадәр тапшыра ала.

**Ахыры 2нче биттә.**



Алия Галимуллина фотосы

• Бәйге

# Фән киңлекләре чиксез

**Динара ӘХМӘТОВА,**
хәбәрче

10 февраль көнне Казан федераль университетының Актлар залында «2011 елның иң яхшы яшь галиме» республика конкурсының финалчыларын һәм җиңүчеләрен тәбрикләү тантанасы узды.



Алия Галимуллина фотосы

Фән – ул бик авыр һәм бик аңлашылып бетми торган әйбер. Ул вак кына хатаны да кичермәскә мөмкин, дип уйлый күпләр һәм аңа алынырга да курка. Ә фән белән шөгыльләнүче, көн саен яңа ачышлар ясаучы галимнәргә сокланып карыйм мин. Алар әле минем яшьтәшләрем дә булса...

Яшь галимнәр хәрәкәте үз рәтенә 10 меңнән артык кешене берләштерә. Ул 1995 елның 14 апреленнән бирле хезмәт күрсәтә. Алар, фәнни оешмаларны берләштерү, фән, тикшеренү һ.б. иҗади өлкәдә төбәкара һәм халыкара бәйләнеш булдыру максатыннан, конференцияләр, «түгәрәк өстәл»ләр, фәнни-популяр лекцияләр уздыра. «Иң яхшы яшь галим» конкурсы беренче мәртәбә 2010 елда уздырыла. Ул фундаменталь һәм гамәли фәнне үстерүгә зур өлеш керткән талантлы яшьләрне барларга ярдәм итә. Быел барлыгы 250 гариза арасыннан финалга 30 конкурсант үтте. Җиңүчеләрне 3 номинация буенча бүләкләделәр.

Бүләкләү тантанасын КФУ ректоры Илшат Гафуров ачып җибәрде. Ул уку йортында фәнни эшчәнлек өчен тормышка ашырылып килгән яңа шартлар, яшь галимнәргә бирелә торган матди ярдәм турында сөйләде. «Безнең лабораторияләрдә, фәнни үзәкләрдә уку йортыбызның тәҗрибәле галимнәре генә түгел, ә сез дә шөгыльләнә, идеяләрегезне тормышка ашыра аласыз. Хәзерге заманда фән белән шөгыльләнү табышлы да, дәрәҗәле дә, лаеклы да», – диде ректор барлык конкурсантларны котлап.

«Социо-гуманитар фәннәр» номинациясендә КФУдан Азат Сафиуллин дипломга лаек булды. Язмалар, монографияләр саны, Татарстан, Россия һәм халыкара грантлар исәпкә алынды.

«Техник фәннәр» номинациясендә җиңүчеләрне бәяләү өчен башка критерийләр исәпкә алынды: галимнәрнең, монографияләр бастыру һәм грантлар алудан тыш, федераль программаларда катнашуы мөһим.

«Табигый фәннәр» номинациясендә катнашучы галимнәр арасыннан жюрига иң-иңнәрне сайлау җиңел булмагандыр. Алда санап үтелгән критерийләргә Хирш һәм цитаталаштыру индексы өстәлә. Бу галимнең публикацияләр санының гомуми күләмен күрсәтә. Диплом белән бездән Анатолий Мокшин, Максим Трушин һәм Гүзәл Зыятдинова бүләкләнде. «Табигый фәннәр өлкәсендә иң яхшы яшь галим» исеменә һәм 25 мең күләмендә премиягә КФУның биология һәм туфракны өйрәнү факультеты микробиология кафедрасының өлкән укытучысы Равил Фәхруллин ия булды. «Фәндә хәзер чикләүләр юк. Бүген барыбыз өчен дә фән – бердәм өлкә. Без үзебезнең республиканы, илне халыкара аренада тиешле дәрәҗәгә чыгара алырбыз дип уйлыйм», – диде яшь галим. Һәр җиңүче конкурсны оештыручыларга һәм вуз җитәкчеләренә рәхмәт сүзләре җиткерде.

Финалга үткән галимнәр көчләрен Идел буе федераль округы күләмендә узачак конкурста сынап караячак. Аларга тагын да зур уңышлар һәм яңа җиңүләр телибез! Шулай ук фән өлкәсенә һәркем өчен ишекләр ачык икәнен һәм аның киңлекләренең чиксез булуын онытмагыз!

• Сайлаулар - 2012

# Гаделлек сагында

**Башы 1нче биттә.**

Президент сайлауларыннан беркем дә читтә калмый. 14 февраль көнне Алабуга филиалында Яшь сайлаучы мәктәбе кысаларында «Эшлекле уен» узды. Уенга мәртәбәле кунаклар: ТР Дәүләт Советы депутаты Илсур Сафиуллин, Алабуга шәһәренең территориаль сайлау комиссиясе җитәкчесе Андрей Смирнов килде. Катнашучылар Президент сайлаулары турында яңа мәгълүматлар белән таныште.

Илсур Сафиуллин хәзерге Россиянең актуаль проблемалары турында сөйләде, кандидатларның кайбер программалары белән таныштырды. Аның фикеренчә, Россиянең киләчәгенә дөрес адым ясау өчен, бүгенге көнен аңларга кирәк. Депутат шулай ук сорауларга да җавап бирде. Андрей Смирнов үз чыгышында: «Без президент түгел, ә тотрыклы киләчәгебезне сайлыйбыз», – диде. Шулай ук һәр кеше үз тавышын бирергә тиешлеген ассызыклады.

Яшьләрнең җәмгыять фәне буенча белемен тикшерү өчен, викторина оештырылды. «Тарихчылар» һәм «Юристлар» арасында сәяси дебат күрсәтелде.

Чараның йомгаклау өлешендә Яшь сайлаучы мәктәбе җитәкчесе доцент Владимир Жадан чыгыш ясады. Аның сүзләренчә, мәктәпнең төп бурычы – сәяси тәрбия бирү, чөнки киләчәкне без үзебез сайлыйбыз.



• Премьера

# «Беренче мәхәббәт» онытылмый!

**Алисә БИЛАЛОВА,**
хәбәрче

1 март көнне Филология һәм сәнгать институтының актлар залында «Мизгел» яшьләр театрының чираттагы премьерасы.




Быел театрның режиссеры, РФнең атказанган, ТРның халык артисты Марсель Җаббаров Хәй Вахитның «Беренче мәхәббәт» пьесасын кабат сәхнәгә кайтара. Ни өчен кабат дим, чөнки инде моннан 10-12 еллар элек ул аны сәхнәләштергән булган. Мин режиссерның ни өчен яңадан бу әсәргә әйләнеп кайтуы белән кызыксындым. Баксаң, ул бүгенге тормыш, киләчәк өчен борчыла икән. «Тормыштан мәхәббәт, ярату, сагыну кебек төшенчәләр китеп бара. Җәмгыятьтә, гаилә, ата белән бала, егет белән кыз арасында да юк дәрәҗәсендә хәзер алар. Ә бит нинди авыр ачлык, сугыш елларында да кешеләр бу хисләрдән ваз кичмәгәннәр, аларны саклап калганнар. Хәзер тормышыбыз житеш, ачлык, газап дигән нәрсәләр күбебезгә ят. Кешеләр рухи якны түгел, ә матди якны күбрәк кайгырта. Хәй Вахитның әлеге әсәрендә болар барысы да бар. Сәхнәдә генә булса да шул илаһи хисләрне кабат күрәсем килде», – ди режиссер. «Быелгы спектакль беренче тапкыр куелганыннан бик нык аерыла. Ул вакытта әле минем режиссер буларак осталык, тәҗрибәм аз иде, хәзер инде бөтенләй икенче күзлектән сәхнәләштердем», – дип искәртте Марсель Җаббаров.

Менә инде икенче спектакльдә (узган елгы премьерада да) тулаем Илназ Баһның җырларын кулланалар мизгелләр. «Алар нәкъ шушы спектакльгә атап язылган кебек килеп чыктылар», – ди Илназ үзе. Танылган яшь җырчы спектакльнең композиторы, баянчысы гына түгел, ә үзе дә уйный – Әпсәләм ролен башкара.

«Әсәрдә сафлык, чисталык, илаһи хисләр дулкыны хөкем сөрә, карап тетрәнерлек булачак», – дип вәгъдә итә Марсель Җаббаров. Димәк, 1 март барчабыз да премьерага!

• Фән дөньясында

Хөрмәтле укучыларыбыз! Без сезне фән өлкәсенә зур өлеш керткән, алай гына да түгел, фәнгә мәхәббәтне буыннан-буынга тапшырып баручы галимнәребез, аларның гаиләләре белән таныштыра башлыйбыз.

# Көчле нәсел





**Динара ӘХМӘТОВА,**
хәбәрче

Шаһидуллиннар династиясе башлыгы Роальд әфәнде дөнья күләменә органик кушылмаларның спектроскопия өлкәсендә ясаган ачышлары белән танылган галим. Ул китапка, гыйлем алуга зур игътибар биргән эшче гаиләсендә туа. Әтисе Рифгать фронтка киткәч, Роальд гаиләдә әнисе, әбисе, сеңлесе Амалия һәм энесе Рөстәм өчен төп ышаныч булып кала.

Аңа исемне җирнең көньяк полюсын ачкан Норвегия сәяхәтчесе Роальд Амундсен хөрмәтенә кушалар. Казан Роальды да үз олимпларын бик иртә ача башлый. Фронтка эләгү өчен, ашыгыч рәвештә мәктәпне тәмамлый. Бәхеткә Җиңү килә, егетне сәяси эшчәнлек җәлеп итә. Ләкин ул үзен фәнгә багышларга уйлый. КДУның физика-математика факультетын тәмамлап, оптик-молекуляр спектроскопияне өйрәнә башлый. Танылган химик Борис Арбузов укучысы Россия Фәннәр академиясе Казан милли үзәге Органик һәм физик химия институтының беренче гыйльми сәркатибе була. Максатчан, лидер, тырыш укучысын Борис Арбузов бик хөрмәт итә һәм алар озак еллар буе бергә эшли.

Бу гаиләдә бөтен балаларга да югары белем бирергә тырышалар. Энесе Рөстәм физика-математика фәннәре докторы, КФУның хисаплау математикасы кафедрасы профессоры. Талантлы галим математика кебек авыр фәнне студентларга кызыклы һәм аңлаешлы итеп өйрәтә белә.

Сеңлесе медицина фәннәре кандидаты Амалия ханым республикада каты авыруларны ачыклау буенча белгеч буларак билгеле. Кызганычка каршы, ул 27 ел элек якты дөнья белән мәңгелеккә хушлаша.

Гадәттә, ике кеше бер юнәлеш буенча барганда гына гаилә гармонияле була, диләр. Роальд әфәнденең тормыш иптәше Аида ханым сөекле хатын гына түгел, ә ышанычлы хезмәттәш тә. Физика-математика фәннәре кандидаты озак еллар дәвамында Россия Фәннәр академиясе Казан милли үзәгенең Органик һәм физик химия институтында эшли.

Бу гаилә учагында тәрбияләнгән Гүзәл һәм Рифгатьнең һөнәрләре дә алдан ук язмышларына язылып куелгандыр, мөгаен. Кызлары балалар табибы, ә Рифгать Татарстан Фәннәр академиясендә Экология һәм табигый байлыклардан файдалану мәсьәләләре институты директоры булып эшли. Аның тормыш иптәше Рәйсә ханым да химия фәннәре кандидаты. Шаһидуллиннар династиясен оныклар да мактаулы рәвештә дәвам итә. Айгөл – Икътисад, идарә итү һәм хокук институтында өлкән фәнни хезмәткәр, физика-математика фәннәре кандидаты Артур Россия Фәннәр академиясе Казан милли үзәгенең оптик спектроскопия лабораториясендә эшли.



Бу династиягә сокланмыйча мөмкин түгел. Алар киләсе елга династия башлыгының 85 яшьлек юбилеен билгеләп үтәргә җыелачак. Роальд әфәнденең оныкчыклары да ул салган юлдан зур үрләр яулар, фән өлкәсендә яңа ачышлар ясар дип уйлыйбыз.

*Материал Татарстан Фәннәр академиясе ярдәме белән эшләнде*

• Сезне бездә көтәләр

# «Очрашулар безгә кирәк!»

**Алисә БИЛАЛОВА,**
хәбәрче

Мәктәпне тәмамлагач нишләргә? Кая барып бәрелергә? Дөрес юлны ничек сайларга? Чыгарылыш сыйныф укучылары өчен иң актуаль сораулар бу хәзер. Сабанда сайрамасаң, ындырда ыңгырашырсың, дигән халык мәкален дә нәкъ менә аларга атап әйтергә буладыр. Уку елы башыннан ук хәстәрен күрмәсәң, БДИларны ерып чыгармын димә. Укучыларның гына түгел, университет җитәкчелеген дә борчый әлеге мәсьәлә: ничек итеп яхшы, сәләтле укучыларны үзләренә җәлеп итәргә?



Әлеге сорауга җавапны Филология һәм сәнгать институтының татар филологиясе бүлеге бик уңышлы һәм нәтиҗәсе булырлык итеп сайлаган, миңа калса. Шушы көннәрдә бүлекнең иң актив студентларыннан торган состав татар теле һәм әдәбияты буенча республика олимпиадасына килгән укучылар белән очрашты.

Татар телен яратып, алай гына да түгел, аның белән кызыксынып, өйрәнеп, район олимпиадаларында җиңү яулап килгән әлеге укучыларга һәм аларның укытучыларына мәгълүмат рәвешендә әзерләнгән концерт программасын тәкъдим иттеләр. Студентлар бүлекнең данлы үткәне турында сөйләде, бүгенге актив, күңелле тормышны үзләренең сәләтләре белән исбатлады, киләчәккә бергәләп планнар кордылар.

«Татар теле һәм әдәбияты буенча республика олимпиадалары 5 февральдән башланып китте, 22 сенә кадәр дәвам итәчәк. Һәр сменада 140-150 укучы катнаша (татар мәктәпләре, рус мәктәпләренең татар сыйныфлары, гарәп-төрек телләре һәм чит төбәкләрдән килгән укучылар). Биредә укучыларның вакытлары кызыклы, бик тә файдалы үтә», – ди оештыручыларның берсе, ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының милли бүлек хезмәткәре Гәүһәр Әхмәдуллина. Һәр сменада «Ялкын», «Идел», «Сөембикә» кебек журнал, «Сабантуй» газетасы редакцияләре вәкилләре, «Сәләт» яшьләре, Нәбирә Гыйматдинова, Рүзәл Мөхәммәтшин кебек төрле язучы-шагыйрьләр белән очрашулар оештырыла, төрле ял итү программалары төзелә. «Татар филологиясе бүлеге студентлары, укытучылары килә дигәч, һәр кеше инде иртәдән бирле көтә, бигрәк тә әлеге бүлекне тәмамлаган укытучылар», – дип ачык йөз белән каршы алды ул. – «Һәр укучы белән очрашу, сөйләшү кирәк. Биредә бит милләтебезнең киләчәге булырдай укучылар утыра. Татар филологиясе бүлегендә белем бирү дәрәҗәсе югары, баланы төрле яклап үстерергә сәләтле укытучылар эшли. Минем улым белән кызым да шунда укып чыктылар, шуңа да мин бу бүлек турында бик күп сөйли алам», – ди Гәүһәр Габделхак кызы. Аның бу сүзләре мактау гына түгел, ә укучыларга чакыру буларак та яңгырады.

Гөлүсә Гәрәева, Роза Асылгәрәева кебек мөгаллимнәр, укучылар алдында чыгыш ясап, бүлек турында сөйләде, 2012 елга булган яңалыкларны җиткерде. Җыр, бию, нәфис сүз белән үрелеп барган әлеге очрашу барчабызның да күңелендә җылы, уңай тәэсирләр генә калдыргандыр дип уйлыйм.

«Бүлегебезнең киләчәге, аның үсеше, активлыгы турында уйлаганда, Татарстанның төрле төбәкләреннән килгән, татар телен, әдәбиятын сөюче милләтпәрвәр укучылар белән очрашулар безгә бик кирәк. Алар белән бергә булганда гына без татар дигән бөек милләтне саклап кала алабыз. Яңа уку елында әлеге укучылар белән татар филологиясе бүлеге бинасы кысаларында очрашулар насыйп булсын», – ди очрашуны оештыручы Дамир Хөснетдинов.

• Кечкенә галимнәр

# Көянтә

**Рифә РАХМАН**

**(Ахыры. Башы 1-3 (14-16) саннарда)**

Массаж ясаучы ханым, юллама биргән табибә кебек, кулга каты, телгә коры булып чыкты. Безнең як чишмәләреннән су эчкәнгә охшамаган, дип, эченнән генә көлгән кебек итте Сусылу.

– Ятыгыз. Менә шулай. Гәүдәгезне таралдырып җибәрегез. Тәнегез утын пүләне кебек! Я тыңлыйсызмы әйткәнне, юкмы?! Әллә миннән чирканасыз инде? Аркагызны җыерасыз, болай каткан җилкәләрне ничек йомшартыйм, – дип башлады ул сүзен, Сусылу сөякләренә үтәргә юл тапмагандай.

– Һич чирканмыйм. Үзем дә шул тәнем йомшамасмы дип, Сезгә килгән бит инде.

Сусылу алай итенде, болай – таралмаса да таралмас икән тәне. Ярый артык хәсрәтле көне түгел. Кушеткага таш кебек ишелеп кенә төшкән булыр иде.

– Ярар. Тора-бара йомшап китмәсме әле? Авыр атлетика белән шөгыльләнмисездер ич?

– Юк.

– Һмм... Штанга күтәргән кеше җилкәсенә охшаган. Көянтә фәлән дә, көне-төне йөк ташымасаң, бу кадәр җилкәне таушалтмас. Җитмәсә, буйдан-буйга остеохондроз үзегездә, сколиоз. Кем булып эшлим дидегез әле? Трамвай йөртүчеме? Урам себерүчеме?

– Университетта укытам.

– Шулайдыр инде! Бүлмәгә керешегезгә кадәр ирләрнеке. Янымнан үтеп киткәндә, җилегез ега язды бит! Университет аксөякләре мондый булмас.

– Менә мин – шундыйларның берсе. Фән белән шөгыльләнүче кухарка, шофер, балта остасы...

Сусылу бу исемлекне әллә никадәр суза ала. Массажист ханым аны шаярта дип аңлады, үзе дә сүзен шул рухта дәвам итте:

– Ленин белән өмәдә бүрәнә ташучының берсен һаман да ачыклый алмаганнар диме. Шул Сез булгансыздыр инде ул.

– Ленин заманында торсам, бүрәнә ташымас идем лә мин. Приказщик бабаларымның түр сәкесендә чигү чигеп утырган бер иркәҗан булыр идем.

– Алайса, һичьюгы авыл кызы инде сез, төне буе кырдан – бәрәңге, амбардан ашлык урлагансыздыр әле. Көянтә күтәреп.

Инде оныттым гына дигәндә, тагын шул көянтә. Нәрсәсе ошамый торгандыр аның табибларга?! Үзләре шәһәрдән чыккан диярсең! Күзләренә тулган яшьне Сусылу мендәр читенә сөртте. Массажистка аркасына чалкан ятарга кушкан иде. Галимә ханымның тирән күзләренә тулган яшьне күреп, ис-акылы китте.

– Ну нинди кешеләр бу авырулар?! Имгәнмәгән җирләре юк. Барысына түзәләр, синең йомшак кына массажлавыңа да чыдамыйлар. Көянтә кебек сыгылалар.

Ие шул. Ни дип елап тора әле. Кеше сөендереп. Дәвалаучыдан көлдереп. Күзләренең нигә яшьләнгәнен әйтсә, кычкырып көләчәк кенә бит! Иреннән аерылган, тормышны кул көче белән тарткан массажистка тел белән акча тапкан галимәнең көянтәдән аерылу хәсрәтеннән елавын аңлармы? Көянтә бирмәк – ир бирмәк түгел, генә диячәк! Көянтә бирмәк тә җан бирмәк була ала икән! Синең өчен кадерле, хатирәле көянтә булса!

Таңда өзелгән телен кесәсенә салып, көн буе урман кискән, эшен бетермичә, табибка да бармаган бабасы каршында оят! Эше дә, ә бит ашы да – көянтәдән! Табиблар авыруларың да, димәкче. Нәрсә белә соң алар?!

● Гашыйклар көне

# «Изге Вәли көне белән!»

**Динара ӘХМӘТОВА,**
хәбәрче



Соңгы елларда февраль аеның салкын көннәрен тагын бер бәйрәм җылыта. Бу көнне кызлар да, егетләр дә мәхәббәт аңлатудан оялып тормый. Ләкин нигәдер аны Изге Вәли көне дип атыйлар. Минем өчен ул Гашыйклар яисә Мәхәббәт көне буларак якын.

Изге Вәли көненең 16 гасырдан артык тарихы бар. Бәйрәмнең үз хуҗасы – христианнарның изге атакае Валентин. Бу дата якынча 269 ел белән билгеләнә. Рим империясе белән Клавдий II идарә иткән чорда армия солдатларга кытлык кичерә. Аның фикеренчә, бу сугышчыларның гаиләгә игътибарны күбрәк бирүе белән аңлатыла. Нәтиҗәдә, ул легионерларга өйләнергә ярамый дигән Указ чыгара. Моның белән генә солдатлар гашыйк булудан туктамый һәм алар бәхетенә императорның ачуыннан да курыкмастай кеше табыла. Терни шәһәреннән Валентин исемле атакай яшерен рәвештә гашыйк җаннарны кавыштыра торган була. Император әлеге яшерен эшләр турында ишеткәч, Валентинны үлем җәзасына тарта. Рим Папасы Геласиус 496 елда 14 Февральне Изге Валентин көне дип игълан итә.

Бу көнне һәр ил үзенчә бәйрәм итә. Көнбатыш Европада ул XIII гасырдан, АКШта 1777 елдан башлап үткәрелә. Япониядә бу көнне баллы әйбер бүләк итү традициясе сакланган. Биредә ул күпмедер дәрәҗәдә «ир-атлар өчен 8 март»ны хәтерләтә, чөнки алар бүләкне нәфис затларга караганда күбрәк кабул итә. Французлар Изге Вәли көнендә кыйммәтле әйберләр, даниялеләр кипкән ак чәчәкләр бүләк итеп бирә. Британиядә кияүгә чыкмаган кызлар бу көнне кояш чыкканчы ук тора һәм, тәрәзә каршына барып, егетләрне күзли башлый. Иң беренче булып очраган егет аларның булачак тормыш иптәше дигән ышану яши. Изге Вәли көнен уздырмый торган бердәнбер ил – ул Согуд Гарәбстаны. Монда ул рәсми рәвештә тыела. Русиядә дә гашыйкларның үз бәйрәме булган, ләкин җәй башында уздырылган. Аның нигезендә Петр һәм Феврония мәхәббәте ята һәм Купала вакытына туры килә.

Бүген бу бәйрәм бездә дә бик популяр, аеруча яшьләр арасында. Superjob.ru сайты үткәргән сораштыруларга караганда, быел россиялеләрнең 39%ы бәйрәмне зурлап уздырачак. 2011 ел белән чагыштырганда, бу 2%ка күбрәк дигән сүз. Бәйрәмгә 44% каршы килүчеләр бу көннең килеп чыгышын кабул итеп бетерми яисә Ватанны саклаучылар һәм Халыкара хатын-кызлар көне белән артык якын, дип фикерләрен җиткерә. Кайберәүләр уйлавынча, яраткан кешеләр бер-берсе өчен көн саен бәйрәм ясарга тиеш.

Бүләкләргә килгәндә, хатын-кызлар арасында елдагыча шәмнәр янында кичке аш оештыру иң беренчеләр рәтендә (24%), ә егетләр сөйгәннәрен чәчәк бәйләмнәре белән сөендерә (31%). Шулай ук бизәнгеч әйберләр, кино, театр һәм концертка билет кебек бүләкләр дә күпчелекне алып тора. Кием-салым, шигырьләр һәм йорт хайваннары да бүләк итәләр икән. Россиялеләрнең 17%ы парларына бернәрсә дә бирми, 15% кеше, гомумән, бу көнне бәйрәмгә санамый.


Дини җәмәгатьчелек «бәйрәм»гә тискәре карашта. Аңа ислам дине вәкилләре генә түгел, православие һәм католик динен тотучылар да каршы. Алар фикеренчә, бу көннең нигезендә «луперкалий» дигән мәҗүсиләр бәйрәменең бозыклыгы ята.

Кызганычка каршы, без инде бу коткыга биреллдек. Әлеге бәйрәмне Белем, Әниләр яки Өлкәннәр көненә караганда да зурлап бәйрәм итәбез. Ул безгә Җиңү көненә караганда да кадерлерәк. Бәлки әле күпләр 14 февраль ил күләмендә «компьютерчиклар» яисә «виноград көне» икәнен белмидер дә. Шулай шул, «Изге Вәли көне белән!» – дип котлаучыларга, елмаеп: «Рәхмәт. Сезне дә Гашыйклар көне белән», – диярга туры килә.

● Дөнья үзебезнеке

# «BREAK ART CREW» яки брейк-данс биибезме?

**Зилә ФӘСХИЕВА,**
хәбәрче



Бу елларда бер дустым «Банзай» төнге клубына чакырды. Ниндидер кызыклы фестиваль була, бик күп кеше киләчәк, танылган ди-джейлар, биюләр... дигәч, ризалаштым инде. Бертөрлелек туйдыра бит, барып, карап булса да кайтырмын дип чыгып киттем.

Ә анда... мин көткәннән дә текәрәк шоу инде башланган иде! «BREAK ART CREW» брейк-данс командасының өч яшьлек юбилеен билгеләп үтәргә Казаннан гына түгел, Магнитогорск, Мәскәү кебек эре шәһәрләрдән дә кунаклар килгән. Мондагы яшьләрдән энергия ташып тора, барысы да хәрәкәтчән, күзләрендә ут уйный. Тагын шуңына игътибар иттем: брейк-дансчылар бер-берсенә карата дустанә, җылы мөнәсәбәттә. Минем, гадәттә, дискәтүкләргә киеп йөри торган классик киемем бу атмосферага бик үк туры килми булып чыкты. Яшьләр барысы да иркен, уңайлы, урам стилендәге киемнәрдән иде.

Брейк-данс... Ни дигән сүз соң ул? Интернет челтәрендәге эзләү төймәсенә бастым. Брейк-данс хип-хоп культурасының бер агымы, урам биюләренең бер төре дигән сүз икән. Аның үз кагыйдәләре, терминнары бар. Бу стиль иреклелек, беркемгә дә бәйле булмаганлыкны аңлата. Брейк-данс берничә этаптан тора: Footwork – аякларның бик тиз хәрәкәтләнүе, Top rock – гәүдәнең өске өлешләре хәрәкәте һәм Freezes берничә секундка бер позада селкенмичә тору дигән сүз.

Үз гомеремдә дә мондый төрдәге биюләр белән шөгыльләнгәнем булмаса да, кызыгып карап тордым. Аларның сыгылмалылыгы, күз ачып йомганчы, бер элементтан икенчесенә күчүе, чыннан да, зур әзерлек таләп итә торган хезмәттер.

Брейкчылар фестивале ярыш формасында барды. Кара-каршы чыгып, бер-берләренә катлаулырак күнегүләр белән «һөҗүм» ясый тордылар, ә жюри алар арасыннан иң-иңнәрен сайлап алды. Җиңелсәләр дә, кәефсезләнмиләр, ә кул бирешеп, бер-берләренә рәхмәтләрен белдерәләр! Менә бит алар нинди урам биюләре белән кызыксынучы яшьләр! Тәрбиясез яки дорфа дигән уй һич кенә дә булырга мөмкин түгел! Аерым-аерым чыгыш ясаганда, «Little Foot» командасына, парлы чыгышларда – «Top and foot-Splinter and Lubava» һәм бишәр кешедән торган батлда («батл» – инглиз сүзе, ярыш мәгънәсендә) «Splinter, Barak, Zip-Rock STP КачЭля» командасына өстенлек бирелде. Ә фестивальне оештыручы егетләр Адель һәм Марсель, әлегә мәктәптә генә укысалар да, инде үз карашлары, кечкенә генә проектлары бар. Бу төр биюләр белән кечкенәдән кызыксыналар, максатчаннар. Бер төркем яшьләрне җыя алганнары, кызыклы очрашуларга омтылганнары өчен афәрин! Казанда мондый төркемнәр тагын бар, әлбәттә, «BREAK ART CREW» алар арасында иң уңышлы эшләп килүчеләрнең берсе дип беләм!

Дөрестән дә, кирәкме соң мондый төрдәге биюләр, дияр кайберәүләр. Минемчә, кирәктер... Кеше характеры очсыз-кырыйсыз үзенчәлекләргә ия, кемнәрдер ирекне, кемнәрдер гаугалы компанияләрне, ә кемнәрдер ялгызлыкны өстенрәк күрә. Вакытларын ничек уздырырга белмичә, сыраханәләрдә утырганчы, хип-хопның бу төре белән шөгыльләнү, хәрәкәттә булу, үзеңнең фикердәшләреңне табу күпкә яхшырактыр. Энергия, креативлык, үзенчәлекле була белү – яшьлекнең иң төп сыйфатлары бит, дуслар!

## *Котлыйбыз!*

**Сиринә ТРОФИМОВА,**
хәбәрче



*Февраль аеның салкын бер кыш көнендә тугангамы, күптәнге танышым, элеккеге хезмәттәшем Мөнирә Хәлилрахман кызы Әнвәрова башкалардан үзенең тыйнаклыгы, җитдилеге, төгәллеге белән аерылып тора.*

*Кечкенәдән үк укытучы булырга хыялланган Мөнирә ханым, үз сукмагыннан бер дә тайпылмыйча, Казан дәүләт университетын 1988 елда тәмамлап, хезмәт юлын да шушында башлап җибәрә. Бүген дә ул – КФУның Филология һәм сәнгать институтында хәзерге татар теле һәм аны укыту методикасы кафедрасының өлкән укытучысы. 24 ел буена Мөнирә Хәлилрахман кызы студентларының яраткан укытучысы. Беренче чиратта, үзенә һәм аннан башкаларга таләпчәнлеге, һәрдаим белемен камилләштерүе, гамәли психологияне яхшы белүе ошый, ди укучылары. Бу фикерләрне куәтләп, Мөнирә ханымның Татарстан һәм Россия төбәкләрендә яшәүче татар теле һәм әдәбияты укытучылары күңелендә дә зур урын алуын әйтергә кирәк. 1998 елдан башлап ул ТРның Мәгарифне үстерү институтында үткәрелә торган квалификация күтәрү курсларында һәм укытучыларга өстәмә белгечлек бирелә торган махсус факультетта да белем бирде. Хәзер дә укытучылар белән тыгыз элемтәдә яши.*

*Мөнирә ханым бәхетле кешеләр аңлый торган зур серне – ятатып яшәү һәм эшеңне яратып эшләүне белүчеләрдән. «Ирем Нәгыйм, улым Нияз, киленем Ләйлә, сөеп туймый торган оныгым Кәримем яшәргә, эшләргә илһам, көч һәм дәрт биреп торганда, укыйсы, өйрәнәсе, күбрәк беләсе килгән студентларым булганда, мин бәхетлемен», – ди ул. Гомер бәйрәме – юбилее уңаеннан, хезмәттәшләренең котлавына без дә кушылабыз!*

***

*12 февраль көнне укытучыларның хөрмәтле коллегасы, студентларның яраткан остазы, хәзерге татар тел белеме һәм укыту методикасы кафедрасының өлкән укытучысы Мөнирә Хәлилрахман кызы ӘНВӘРОВАга 50 яшь тулды.*

*Хөрмәтлебез! Сезне юбилеегыз белән ихлас котлыйбыз!*

*50 яшең килеп ишек каккач,*
*Мендем димә яшьнең түренә,*
*Күңелеңдә калсын яз чуагы,*
*Гомер үтә диеп сүрелмә.*
*Котлы булсын синең туган көнең,*
*Шатлык белән үтсен һәр көнең,*
*Корычныкы булсын тазалыгың,*
*Кояшныкы булсын гомерең.*

Филология һәм сәнгать институтының хәзерге татар тел белеме һәм укыту методикасы кафедрасы коллективы

Филология һәм сәнгать институты җитәкчелеге, мөгаллимнәр, татар филологиясе бүлеге студенты **Алсинә Раузит кызы Фазылҗанованың** фаҗигале үлеме сәбәпле, мәрхүмәнең әти-әнисе, туганнары, төркемдәшләренең тирән кайгысын уртаклаша.

DARELFØNYN университет
Тираж 999

Мөхәррир – Рамил Гомәр улы Ханнанов
Иҗат коллективы: С.М.Трофимова, Д.Р.Әхмәтова, А.И.Билалова, З.Ф.Фәсхиева
Биткә салу һәм дизайн буенча белгеч – Г.З.Камалиева

Газетаны гамәлгә куючы – Казан (Идел буе) федераль университеты
Редакция һәм нәшрият адресы: 420021, Казан ш., Профессор Нужин ур., 1/37 йорт, 318 каб.
Хәбәрләшү өчен телефон: 89053711571.
Электрон почта: darelfonyn@mail.ru Сайт: ksu.ru

Бастырылуга кул кую вакыты: график буенча – 16.00, кул куелды – 16.00
«Карти» ҖЧҖ типографиясендә басылды, Казан ш., Восстание ур., 60 й.
Газета бушлай таратыла